РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.08.2017 № 1026-п

«Игезәкләр туганчы аналарга матди ярдәм күрсәтү турында» Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 26.01.2013 № 46-п карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Дәүләт социаль ярдәме турында" 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон һәм "Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында" РФ Хөкүмәтенең 2017 елның 14 февралендәге 181 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында Саба муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 26 гыйнварындагы 46-п номерлы «Игезәкләр туугa аналарга матди ярдәм күрсәтү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 пунктлар өстәргә:

«4. Әлеге карар нигезендә социаль ярдәм чараларын күрсәтүче органнар күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - ЕГИССО) куллану юлы белән һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматларга туры китереп бирү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәләр.

5. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат ЕГИССО Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә ЕГИССО куллану юлы белән һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә алынырга мөмкин.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Җитәкче Р.М. Гасимов